ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата әзерләнгән генераль планның проектын карау срогы җирле үзидарә органыннан тиешле документлар кергән көннән алып җиде эш көненнән дә артмаска тиеш.»;

2) 4 өлештә «ул кергән көннән алып утыз көн дәвамында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан проектны карау срогы җирле үзидарә органыннан тиешле документлар кергән көннән алып җиде эш көненнән дә артмаска тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 03 март
№ 3-ТРЗ